**ГЛАВА ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның 19 ноябре № 7

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» гражданнар җыенының 14 октябрь 2025 ел № 1 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 1 статьясы, Россия Федерациясе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» гражданнар җыенының 2025 елның 14 октябрендәге № 1 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2025 елның 1 декабрендә 9 сәгать 00 минутка Шахмай АМЙда (Үзәк урам, 45 йорт) гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыеннарын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә» сүзләренә алмаштырып, гражданнар җыенының 2025 елның 14 октябрендәге № 1 карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы»

«ӘЙЕ» «ЮК».».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: https://novosheshminsk.tatarstan.ru, гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай

авылы, Үзәк урам, 47 нче йорт янындагы мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы Н.М. Илалова

СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ